| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«СТАРОШУГУРОВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ИСКЕ ШӨГЕР<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның 2 октябре № 7

Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлегенең Иске Шөгер авыл торак пунктында гражданнар җыенының 2024 елның 23 ноябрендәге 3нче, 4нче номерлы карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында (2025 елның 7 августындагы 1, 2 номерлы редакциядә)

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (29.11.2023 №1532 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлегенең Иске Шөгер авыл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 23 ноябрендәге 3 номерлы һәм «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлегенең Иске Шөгер авыл торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында» 2024 елның 23 ноябрендәге 4 номерлы карарларына (2025 елның 7 августындагы 1, 2 номерлы редакциядә) үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2025 елның 13 октябренә 14 сәгать 00 минутта билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлегенең Иске Шөгер авыл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 23 ноябрендәге 3 номерлы һәм «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлегенең Иске Шөгер авыл торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында» 2024 елның 24 ноябрендәге 4 номерлы карарларына (2025 елның 7 августындагы 1, 2 номерлы редакциядә)түбәндәге үзгәрешләр кертү белән килешәсезме:

4 пунктчада) «К. Маркс» сүзләреннән соң «,Тукай, Мурзин»сүзләре белән тулыландырырга.

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Шөгер авылы Совет ур., 1 йорт үзидарә администрациясе бинасында, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Иске Шөгер авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Л.М.Шиһапова